КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2021 ел, 18 июнь

г.Казань

№ 473

«Ворлдскиллс» технологияләр үзәге» һөнәри осталыкны үстерүнең коммерциягә карамаган автоном оешмасы төзү турында

Россия Федерациясендә «Ворлдскиллс» хәрәкәтен үстерү, «Ворлдскиллс» стандартлары буенча эталон әзерлек программаларын эшләү, апробацияләү һәм гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. «Һөнәри осталыкны үстерү агентлыгы (Ворлдскиллс Россия)» автоном коммерциягә карамаган оешмасының, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының «Ворлдскиллс» технологияләр үзәге» һөнәри осталыкны үстерүнең автоном коммерциягә карамаган оешмасын (алга таба - Автоном оешма) төзү турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына:

Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән Автоном оешманы гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга;

30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Автоном оешманың күзәтү советы составы буенча тәкъдимнәр кертергә;

30 көн эчендә Автоном оешма уставын расларга һәм Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә аны дәүләт теркәвенә алуны тәэмин итәргә;

Автоном оешма төзүгә бәйле чаралар үткәрергә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин